**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**№ 94** **2018 ел, 24 сентябрь**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәләләр буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

“2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне башкару өчен яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешедән 300,0 сум үзара салым кертү белән килешәсезме:

***Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру.**

*** Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру.**

*** Күмү урыннарын карап тоту.**

ӘЙЕ ЮК»

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк урамы, 1нче йорт, Шәпкә авылы, Клуб урамы, 14нче йорт,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

1. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә  калдырам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге Советы Рәисе И.Х. Шиһабеев